ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 178-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан кертелгән «2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» 178-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы

АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

М.Г. Әхмәтов

Казан шәһәре
2026 елның 8 июне
№ 633-VII ДС

Проект

Закон чыгару инициативасы хокукы субъекты – Татарстан Республикасы Рәисе

**2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 93 233 691,6 мең сум һәм чыгымнар буенча 92 612 094,1 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан артып киткән күләмен 621 597,5 мең сум итеп, түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

1) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары буенча әлеге Законга 1 нче кушымта нигезендә;

2) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре буенча әлеге Законга 2 нче кушымта нигезендә;

3) Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары структурасы буенча әлеге Законга 3 нче кушымта нигезендә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

«2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

**2025 елгы**
**Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты кытлыгын эчке финанслау чыганаклары**

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Акчалар чыганагының исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 000 01 00 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар кытлыкларын эчке финанслау чыганаклары | - 621 597,5 |
| 000 01 05 00 00 00 0000 000 | Бюджетлар акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчаларны үзгәртү | - 621 597,5 |
| 000 01 05 00 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган акчаларын арттыру | - 98 784 930,9 |
| 000 01 05 02 00 00 0000 500 | Бюджетларның калган башка акчаларын арттыру | - 98 784 930,9 |
| 000 01 05 02 01 00 0000 510 | Бюджетларның калган башка акчалата чараларын арттыру | - 98 784 930,9 |
| 395 01 05 02 01 09 0000 510 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын арттыру | - 98 784 930,9 |
| 000 01 05 00 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган акчаларын киметү | 98 163 333,4 |
| 000 01 05 02 00 00 0000 600 | Бюджетларның калган башка акчаларын киметү | 98 163 333,4 |
| 000 01 05 02 01 00 0000 610 | Бюджетларның калган башка акчалата чараларын киметү | 98 163 333,4 |
| 395 01 05 02 01 09 0000 610 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларының калган башка акчалата чараларын киметү | 98 163 333,4 |

«2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы Законына 2 нче кушымта

**2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты керемнәре**

(мең сумнарда)

| Бюджет классификациясе кодлары | Керем исеме | Суммасы |
|---|---|---|
| 000 1 00 00000 00 0000 000 | Салым керемнәре һәм салым булмаган керемнәр | 170 322,0 |
| 395 1 13 00000 00 0000 000 | Түләүле хезмәт күрсәтүләрдән һәм дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 100 137,0 |
| 395 1 13 02000 00 0000 130 | Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән керемнәр | 100 137,0 |
| 395 1 13 02990 00 0000 130 | Дәүләт чыгымнарын компенсацияләүдән башка керемнәр | 100 137,0 |
| 395 1 13 02999 09 0000 130 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары чыгымнарын компенсацияләүдән бүтән керемнәр | 100 137,0 |
| 395 1 16 00000 00 0000 000 | Штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау | 70 185,0 |
| 395 1 16 07000 00 0000 140 | Дәүләт (муниципаль) органы, бюджеттан тыш дәүләт фонды белән идарә итү органы, казна учреждениесе, Россия Федерациясе Үзәк банкы, Россия Федерациясе исеменнән эш итүче бүтән оешма алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә килешү нигезендә түләнгән штрафлар, неустойкалар, пенялар | 16 398,3 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 1 16 07090 00 0000 140 | Дәүләт (муниципаль) органы, казна учреждениесе, Россия Федерациясе Үзәк банкы, дәүләт корпорациясе алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә килешү нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойкалар, пенялар | 16 398,3 |
| 395 1 16 07090 09 0000 140 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды алдындагы йөкләмәләрне үтәмәгән яисә тиешенчә үтәмәгән очракта закон яисә шартнамә нигезендә түләнгән башка штрафлар, неустойкалар, пенялар | 16 398,3 |
| 395 1 16 10000 00 0000 140 | Китерелгән зыянны (зарарларны) каплау максатларында түләүләр | 53 786,7 |
| 395 1 16 10100 00 0000 140 | Бюджет акчаларыннан законсыз яисә максатка яраксыз файдалану аркасында китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр | 51 306,1 |
| 395 1 16 10100 09 0000 140 | Бюджет акчаларын законсыз яисә максатка яраксыз файдалану аркасында китерелгән зыянны каплауга салына торган акчалата түләтүләр (территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары өлешендә) | 51 306,1 |
| 395 1 16 10110 00 0000 140 | Файда күрүчеләр бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетлары акчаларын алучылар булган иминият очраклары килеп чыкканда зыянны каплау һәм алар карамагында һәм файдалануында булган федераль мөлкәткә китерелгән зыянны башкача каплау | 1 934,8 |
| 395 1 16 10118 09 0000 140 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына күчерелә торган территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды милкендәге һәм файдалануындагы дәүләт мөлкәтенә китерелгән зыянны башкача каплау | 79,2 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 1 16 10119 09 0000 140 | Иминләштерелгән затның сәламәтлегенә зыян китергән өчен җаваплы затларга медицина ярдәме күрсәтүгә чыгымнарны каплау максатларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды керткән дәгъвалар буенча түләүләр | 1 855,6 |
| 395 1 16 10120 00 0000 140 | 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны каплау исәбенә керә торган акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына күчерелергә тиешле керемнәр | 545,8 |
| 395 1 16 10127 01 0000 140 | 2020 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән бурычларны каплау исәбенә керә торган акчалата түләтүләрдән (штрафлардан) 2019 елда гамәлдә булган нормативлар буенча территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына күчерелергә тиешле керемнәр | 545,8 |
| 395 2 00 00000 00 0000 000 | Кире кайтарылмый торган кертемнәр | 93 063 369,6 |
| 395 2 02 00000 00 0000 000 | Россия Федерациясе бюджет системасының башка бюджетларыннан кире кайтарылмый торган кертемнәр | 93 407 349,2 |
| 395 2 02 50000 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 83 606 108,4 |
| 395 2 02 50203 09 0000 150 | Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 1 635 212,9 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 02 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына субвенцияләр | 80 697 939,1 |
| 395 2 02 55257 09 0000 150 | Медицина оешмаларының табиблар һәм урта медицина персоналы хезмәте өчен түләү чыгымнарын финанслашу максатларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына бирелә торган бюджетара трансфертлар | 203 644,5 |
| 395 2 02 55258 09 0000 150 | Халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган бюджетара трансфертлар | 3 000,6 |
| 395 2 02 59999 00 0000 150 | Бюджеттан тыш дәүләт фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 066 311,3 |
| 395 2 02 59999 09 0000 150 | Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларына тапшырыла торган башка бюджетара трансфертлар | 1 066 311,3 |
| 395 2 02 90000 00 0000 150 | Бюджет системасының башка бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган бүтән кертемнәр | 9 801 240,8 |
| 395 2 02 90020 00 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 9 801 240,8 |
| 395 2 02 90029 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына бирелгән кире кайтарылмый торган башка кертемнәр | 9 801 240,8 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 18 00000 00 0000 000 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре | 2 321,4 |
| 395 2 18 00000 00 0000 150 | Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары тарафыннан узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан, шулай ук оешмалар тарафыннан узган еллардан калган субсидияләрне кире кайтарудан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары керемнәре | 2 321,4 |
| 395 2 18 00000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары керемнәре | 2 321,4 |
| 395 2 18 73000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетлары керемнәре | 2 321,4 |
| 395 2 19 00000 00 0000 000 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтару | - 346 301,0 |
| 395 2 19 00000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан кире кайтару | - 346 301,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 395 2 19 55093 09 0000 150 | Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә узган еллардан калган субвенцияләрне территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кире кайтару | - 168 933,3 |
| 395 2 19 55257 09 0000 150 | Медицина оешмаларының табиблар һәм урта медицина персоналы хезмәте өчен түләү чыгымнарын финанслашу максатларында узган еллардан калган бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан кире кайтару | - 387,0 |
| 395 2 19 55258 09 0000 150 | Халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә узган еллардан калган бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына кире кайтару | - 1 395,9 |
| 395 2 19 55849 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән авыручы һәм (яисә) авырый дип шикләнелүче затларга Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фонды акчалары исәбеннән территориаль мәҗбүри медицина иминияте программаларын гамәлгә ашыру кысаларында медицина | - 75,6 |

| | | |
|---|---|---|
| | ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә тиешле территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына бюджетара трансфертлар бирү буенча Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында калган башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан кире кайтару | |
| 395 2 19 55854 09 0000 150 | Мәҗбүри медицина иминияте буенча иминләштерелгән, шул исәптән яңа коронавирус инфекциясе (COVID-19) белән авыручы һәм (яисә) авырый дип шикләнелүче затларга территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын гамәлгә ашыру кысаларында башлангыч медицина-санитария ярдәме күрсәтүне өстәмә финанс белән тәэмин итүгә каралган калган бюджетара трансфертларны Россия Федерациясе территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан кире кайтару | - 32,7 |
| 395 2 19 71030 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге башка субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына кире кайтару | - 173 695,1 |
| 395 2 19 73000 09 0000 150 | Узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан территориаль мәҗбүри медицина иминияте | - 1 781,4 |

| | | |
|---|---|---|
| | фондлары бюджетларына кире кайтару | |
| | Керемнәр, барлыгы | 93 233 691,6 |

«2025 елгы Татарстан
Республикасы Территориаль
мәҗбүри медицина иминияте
фонды бюджеты үтәлеше
турында» Татарстан
Республикасы Законына
3 нче кушымта

**2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты чыгымнары структурасы**

(мең сумнарда)

| Исеме | Бюджет классификациясе кодлары | | | | | Суммасы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | Мин | Рз | ПР | ЦСР | ВР | |
| Гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 00 | | | 492 311,2 |
| Башка гомумдәүләт мәсьәләләре | 395 | 01 | 13 | | | 492 311,2 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары идарә органнары эшчәнлегенең программага кертелмәгән юнәлешләре | 395 | 01 | 13 | 73 0 00 0000 0 | | 492 311,2 |
| Россия Федерациясенең бюджеттан тыш дәүләт фондлары аппаратлары тарафыннан функцияләр башкару | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 0000 0 | | 492 311,2 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 0 | | 374 816,3 |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды аппараты тарафыннан функцияләр башкаруга чыгымнар өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | | 374 816,3 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары тарафыннан функцияләр башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 100 | 303 176,4 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 200 | 66 993,5 |
| Социаль тәэмин итү `һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 300 | 180,2 |
| Башка бюджет ассигнованиеләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 5093 4 | 800 | 4 466,2 |
| Татарстан Республикасы архив фонды документларын һәм башка архив документларын саклауны, комплектлау һәм куллануны исәпкә алуны тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 4402 0 | | 1 000,0 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 4402 0 | 200 | 1 000,0 |
| Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны башка чыганаклар исәбеннән финанс белән тәэмин итү | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 6093 0 | | 23 985,8 |
| Дәүләт (муниципаль) ихтыяҗларын тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр сатып алу | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 6093 0 | 200 | 23 985,8 |
| Эшчәнлекнең башка юнәлешләре | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 9250 0 | | 92 509,1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Дәүләт (муниципаль) органнары, казна учреждениеләре, бюджеттан тыш дәүләт фондларының идарә органнары функцияләрен башкаруны тәэмин итү максатларында персоналга түләү чыгымнары | 395 | 01 | 13 | 73 2 00 9250 0 | 100 | 92 509,1 |
| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 91 969 942,8 |
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 170 550,6 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 04 | 01 0 00 0000 0 | | 170 550,6 |
| Федераль (региональ) проектлар | 395 | 09 | 04 | 01 2 00 0000 0 | | 93 116,9 |
| «Кичектергесез медицина ярдәмен камилләштерү» федераль проекты | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 0000 0 | | 93 116,9 |
| Медицина ярдәме күрсәтү максатларында авиация эшләре сатып алуны тәэмин итүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 5554 0 | | 93 116,9 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка бүтән түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 2 Д6 5554 0 | 300 | 93 116,9 |
| Процесслы чаралар комплекслары | 395 | 09 | 04 | 01 4 00 0000 0 | | 77 433,7 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0000 0 | | 77 433,7 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 0 | | 77 433,7 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | | 77 433,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 04 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 77 433,7 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендә башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 91 799 392,2 |
| «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклауны үстерү» дәүләт программасы | 395 | 09 | 09 | 01 0 00 0000 0 | | 91 799 392,2 |
| Процесслы чаралар комплекслары | 395 | 09 | 09 | 01 4 00 0000 0 | | 91 799 392,2 |
| «Югары технологияле медицина ярдәме һәм профилактика, диагностика, дәвалау һәм реабилитация ысулларын клиник апробацияләү кысаларында күрсәтелә торган медицина ярдәме» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 0000 0 | | 3 408 564,3 |
| Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | | 3 390 563,6 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 R402 0 | 300 | 3 390 563,6 |
| Россия Федерациясе гражданнарына мәҗбүри медицина иминиятенең база программасына кертелмәгән югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүгә финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 0518 0 | | 18 000,7 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 07 0518 0 | 300 | 18 000,7 |
| «Паллиатив медицина ярдәме күрсәтү системасын үстерү» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0000 0 | | 543 296,3 |
| Паллиатив медицина ярдәме күрсәтүгә, шул исәптән балаларга, чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | | 543 296,3 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 09 0202 0 | 300 | 543 296,3 |
| «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы, аның ведомствосына буйсынучы оешмалар эшчәнлеген тәэмин итү, сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка чаралар» процесслы чаралар комплексы | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0000 0 | | 87 847 531,6 |
| Медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 0 | | 6 930 132,8 |
| Махсуслаштырылган медицина ярдәме, ашыгыч, шул исәптән ашыгыч махсуслаштырылган, медицина ярдәме күрсәтүне, медицина эвакуациясен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | | 5 356 073,5 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 3 | 300 | 5 356 073,5 |
| Медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасы белән билгеләнмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 4 | | 1 574 059,3 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0519 4 | 300 | 1 574 059,3 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0529 0 | | 33 018,2 |
| Бюджет учреждениеләренә, автоном учреждениеләргә һәм коммерциячел булмаган башка оешмаларга субсидияләр бирү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0529 0 | 600 | 33 018,2 |
| Россия Федерациясенең башка субъектлары территориясендә иминләштерелгән затларга Татарстан Республикасы медицина оешмалары тарафыннан күрсәтелгән медицина ярдәме | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | | 1 091 216,3 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 0539 0 | 300 | 1 091 216,3 |
| Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 0 | | 79 588 941,5 |
| Татарстан Республикасында медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | | 77 717 201,7 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 1 | 300 | 77 717 201,7 |
| Татарстан Республикасында иминләштерелгән һәм медицина ярдәмен | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | | 1 871 739,8 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| иминләштерү территориясеннән читтә алган затларга медицина ярдәменә түләү өлешендә Татарстан Республикасы территориясендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итү | | | | | | |
| Бюджетара трансфертлар | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5093 2 | 500 | 1 871 739,8 |
| Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондының нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән табиблар һәм урта медицина персоналы хезмәте өчен түләүгә медицина оешмаларына финанслашу чыгымнары | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5257 0 | | 203 619,6 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5257 0 | 300 | 203 619,6 |
| Диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5258 0 | | 603,2 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 09 | 09 | 01 4 12 5258 0 | 300 | 603,2 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 149 840,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | | | 149 840,1 |
| «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасы | 395 | 10 | 03 | 03 0 00 0000 0 | | 149 840,1 |
| Процессы чаралар комплекслары | 395 | 10 | 03 | 03 4 00 0000 0 | | 149 840,1 |
| «Өлкән яшьтәге гражданнарга һәм инвалидларга дәүләт ярдәме чараларын күрсәтү» | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0000 0 | | 149 840,1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| процесслы чаралар комплексы | | | | | | |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | | 143 838,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0521 0 | 300 | 143 838,0 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | | 200,1 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0522 0 | 300 | 200,1 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | | 1 037,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0531 0 | 300 | 1 037,0 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | | 4 765,0 |
| Социаль тәэмин итү һәм халыкка башка түләүләр | 395 | 10 | 03 | 03 4 02 0551 0 | 300 | 4 765,0 |
| Чыгымнар, барлыгы | 395 | | | | | 92 612 094,1 |

**«2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

**АҢЛАТМА ЯЗУЫ**

Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды (алга таба – Фонд) 2025 елгы бюджетны «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 2024 елның 28 ноябрендәге 88-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – Татарстан Республикасы Законы) белән куелган максатлар, Фонд бюджеты чыгымнарының җыелма бюджет исемлеге нигезендә, аңа хисап елы дәвамында кертелгән үзгәрешләрне (алга таба – тәгаенләнгән җыелма исемлек) исәпкә алып үтәде.

2025 елгы Фонд бюджетының керемнәр буенча үтәлеше 93 233,7 млн.сум, яисә Татарстан Республикасы Законы белән расланган күләмнең 99,9 процентын (93 301,2 млн.сум) тәшкил итте.

Фонд бюджеты чыгымнары 92 612,1 млн. сум күләмендә үтәлде, бу Татарстан Республикасы Законы белән расланган күләмнең (95 109,6 млн.сум) һәм тәгаенләнгән җыелма исемлектә каралган күләмнең 97,3 процентын (95 148,9 млн.сум) тәшкил итте.

Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан Фонд бюджеты керемнә бюджетара трансфертлар 80 904,6 млн.сум күләмендә керде, шул исәптән түбәндәгеләргә:

Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә мәҗбүри медицина иминиятен оештыруны финанс белән тәэмин итүгә – 80 698,0 млн.сум;

медицина оешмаларының табибларга һәм урта медицина персоналына хезмәт өчен түләүгә тотыла торган чыгымнарын финанслашу максатларында финанс белән тәэмин итүгә – 203,6 млн.сум;

халыкка диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен үткәрү барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә - 3,0 млн. сум;

Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетыннан кергән акчалар күләме керемнәрнең барлык суммасында 86,8 процент, яисә Татарстан Республикасы Законы белән расланган бюджетара трансфертлар күләменнән 101,1 процент (80 841,9 млн.сум) тәшкил итте.

Татарстан Республикасы бюджетыннан Фонд бюджетына бюджетара трансфертлар 11 436,5 млн. сум күләмендә керде, шул исәптән түбәндәгеләргә:

медицина оешмаларын мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыруга – 9 648,5 млн.сум;

медицина ярдәме күрсәтүнең мәҗбүри медицина иминияте база программасына кертелмәгән өстәмә төрләрен һәм шартларын финанс белән тәэмин итүгә – 1 635,2 млн.сум;

Татарстан Республикасында гражданнарның аерым категорияләренә теш протезлары һәм колак аппаратлары ясау хезмәтләре күрсәтү программасын финанслауга – 152,8 млн.сум.

Татарстан Республикасы бюджетыннан кергән акчалар күләме керемнәрнең барлык суммасында 12,3 процент, яисә бюджетара трансфертларның Татарстан Республикасы Законы белән расланган күләменнән 99,8 процент (11 459,8 млн.сум) тәшкил итте.

Салым булмаган башка керемнәр һәм узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан алына торган керемнәр буенча өстәмә кертемнәр 172,6 млн. сум, яисә керемнәрнең барлык суммасында 0,2 процент тәшкил итте, шул исәптән:

узган елларда файдаланылмый калган акчаларны һәм дебиторлык бурычларын медицина оешмалары тарафыннан кире кайтару – 100,1 млн.сум;

штрафлар, санкцияләр, зыянны каплау – 70,2 млн.сум;

узган елларда файдаланылмый калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтарудан керемнәр – 2,3 млн.сум.

Хисап чорында Россия Федерациясендәге башка субъектларның территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары бюджетларыннан башка бюджетара трансфертлар 1 066,3 млн.сум күләмендә керде.

Керемнәрдә «-» билгесе белән күрсәтелә торган узган еллардан калган максатчан билгеләнештәге субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны кире кайтару 346,3 млн.сум (Федераль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетына – 170,7 млн.сум, Татарстан Республикасы бюджетына – 173,8 млн.сум, Россия Федерациясендәге башка субъектларның территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондларына – 1,8 млн.сум) күләмендә гамәлгә ашырылды.

2025 елгы Фонд бюджеты үтәлешенең төп күрсәткечләре түбәндәге саннар белән тасвирлана:

млн.сумнарда

| Төп күрсәткечләр | Татарстан Республикасы Законы белән расланды | ТР ТММИ фонды бюджеты чыгымнарының тәгаенләнгән исемлеге | Касса үтәлеше | Түбәндәгеләргә карата касса үтәлеше, процентларда: | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Татарстан Республикасы Законына | Тәгаенләнгән исемлеккә |
| Керемнәр, барлыгы | 93 301,2 | | 93 233,7 | 99,9 | |
| Чыгымнар, барлыгы | 95 109,6 | 95 148,9 | 92 612,1 | 97,4 | 97,3 |
| Кытлык | -1 808,4 | | +621,6 | | |

Хисап чорында Фонд бюджеты чыгымнар буенча 92 612,1 млн.сумга үтәлде. Акчалар түбәндәгеләргә җибәрелде:

Медицина ярдәмен түләүсез күрсәтү буенча дәүләт гарантияләре программасы кысаларында күрсәтелгән медицина хезмәтләренә, мәҗбүри медицина иминияте системасында эш алып бару чыгымнарына түләүгә, максатчан программаларны гамәлгә ашыруга – 92 374,9 сум (чыгымнарның барлык суммасында 99,7 процент);

ТР ТММИ фондының нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән медицина оешмаларына табиблар һәм урта медицина персоналы хезмәте өчен түләүгә финанслашу чыгымнарына – 203,6 млн.сум;

диспансеризация һәм профилактик медицина тикшерүләрен уздыру барышында онкология авыруларын ачыклаган өчен медицина хезмәткәрләренә кызыксындыру характерындагы акчалата түләүләрне гамәлгә ашыруга – 0,6 млн.сум;

медицина хезмәткәрләренә квалификация күтәрү программалары буенча өстәмә һөнәри белем бирүне оештыру, шулай ук медицина җиһазлары сатып алу һәм ремонтлау чараларын нормалаштырылган иминият запасы акчалары исәбеннән финанс белән тәэмин итүгә – 33,0 млн.сум;

Фондның вакытлыча янга калган акчаларын кредит оешмаларында депозитларга урнаштыру 2025 елда гамәлгә ашырылмады.

**«2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законы проекты 2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турындагы хисапны керемнәр буенча 93 233 691,6 мең сум күләмендә һәм чыгымнар буенча 92 612 094,1 мең сум күләмендә, керемнәрнең чыгымнардан артып киткән күләмен (Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты профицитын) 621 597, 5 мең сум итеп раслауны күздә тота.

**«2025 елгы Татарстан Республикасы**
**Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалткан дип танылырга, гамәлдә булуы туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яисә яңалары кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокук актлары**
**ИСЕМЛЕГЕ**

«2025 елгы Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында» Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасының кайсы да булса законының һәм башка норматив хокук актларының үз көчен югалтуын тану, гамәлдә булуын туктатып тору, аларга үзгәрешләр кертү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.